ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында” Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында” 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш); 2016, № 3), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“3. 2017 елның 1 гыйнварына муниципаль бурыч күләме җирле бюджет керемнәре күләменең, кире кайтарылмый торган акчаларны исәпкә алмаганда, 100 проценттан артыгын тәшкил иткән муниципаль берәмлекләргә карата 2020 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль бурычның иң чик күләме Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 3 пунктында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән чикләүләрне агымдагы елның 1 гыйнварына бюджет кредитлары буенча муниципаль бурыч күләме кысаларында артып китәргә мөмкин.

Татарстан Республикасына (муниципаль берәмлеккә) карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында һәм 136 статьясындагы 4 пунктында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар кулланылган очракта, Татарстан Республикасы бурычының (муниципаль бурычның) иң чик күләме Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән чикләүләрне агымдагы елның 1 гыйнварына бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт бурычы (муниципаль бурыч) күләме кысаларында артып китәргә мөмкин.

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт бурычының, шулай ук муниципаль бурычның иң югары чиге әлеге өлештә билгеләнгән шартларны үтәп билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 05 март
№ 3-ТРЗ